ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

КАРАР
№ 645

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
“27” 10 2022 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 15 ноябрендәге 729 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 сентябрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 15 ноябрендәге 729 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

2. 4.11 пунктында «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле уку-укыту программаларын исәпкә алып» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле федераль белем бирү программасы» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Мәгариф оешмалары тарафыннан төзелгән уку-укыту программаларының эчтәлеге һәм планлаштырыла торган нәтиҗәләре мәктәпкәчә белем бирүнең федераль программасының тиешле эчтәлегеннән һәм планлаштырылган нәтиҗәләреннән түбәнрәк булмаска тиеш».

3. 5.14 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5.14. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру укучыларның белем ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып, тиешле белем бирү программасының аерым фәннәрен, предмет өлкәләрен тирәнтен өйрәнүне күздә тота ала.»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе В.А. Осокин